**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5720**
**27.08.2021**

Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларның түләүсез туклануын оештыру чаралары турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 20 июнендәге 900 номерлы карары, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2020 елның 15 декабрендәге 3/3 номерлы карары нигезендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның тулы кыйммәтле баланслы туклануын тәэмин итү һәм өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатында

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында түбәндәге категория укучылар өчен түләүсез туклану билгеләргә:

1) 1-4 сыйныф укучылары, шул исәптән күп балалы гаиләдән булган укучылар өчен бер тапкыр түләүсез кайнар ризык;

2) балигъ булмаган 3 һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдә тәрбияләнүче 5-11 сыйныф укучылары өчен бер тапкыр түләүсез кайнар ризык;

3) муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучы инвалид балалар өчен түләүсез кайнар ризык:

- 1-4 сыйныф укучылары өчен - икенче тапкыр түләүсез кайнар ризык;
- 5-11 сыйныф укучылары өчен - ике тапкыр кайнар ризык.

2. Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларны түләүсез тукландыру тәртибе турында нигезләмәне 1 нче кушымтада каралганча расларга.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында каралган чыгымнарны финанслауны 2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Гаиләне һәм балачакны саклау» 10.04 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 35 192 095 сум (утыз биш миллион бер йөз туксан ике мең туксан биш) сум, шул исәптән 03.1.03.05110 максатчан статья буенча 30 949 791 (утыз миллион тугыз йөз кырык тугыз мең җиде йөз туксан бер сум) һәм

03.1.02.25510 максатчан статьясы буенча 2 242 304 (ике миллион ике йөз кырык ике мең өч йөз дүрт сум) күләмендә, 2 нче, 3 нче кушымталарда каралганча расларга.

4. Башкарма комитетның мәгариф идарәсенә тәэмин итәргә:

1) Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба - ЕГИСО) файдаланып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында мәгълүмат җибәрү;

2) ЕГИСОдан файдаланып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә мәгълүмат алу.

5. Муниципаль гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә махсус медицина күрсәткечләре буенча өйдә белем алучы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга азык-төлек җыелмалары бирүне оештырырга.

6. Башкарма комитетның түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру чаралары турында» 2020 елның 7 декабрендәге 6617 номерлы;

2) «Башкарма комитетның «Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру чаралары турында 2020 елның 7 декабрендәге 6617 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 29 гыйнварындагы 595 номерлы.

7. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 27 августындагы
5720 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында
өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларны
түләүсез туклandыру тәртибе турында
нигезләмә

1 бүлек Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларны (алга таба – укучылар) түләүсез туклandыру тәртибе турында нигезләмә «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 20 июнендәге 900 номерлы карары, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2020 елның 15 декабрендәге 3/3 номерлы карары нигезендә эшләнде һәм укучылар өчен түләүсез туклануны (алга таба – туклану) оештыру рәвешендә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибен билгели:

1) 1-4 сыйныф укучылары, шул исәптән күп балалы гаиләдән булган укучылар өчен бер тапкыр түләүсез кайнар ризык;

2) балигъ булмаган 3 һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдә тәрбияләнүче 5-11 сыйныф укучылары өчен бер тапкыр түләүсез кайнар ризык;

3) муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучы инвалид балалар өчен түләүсез кайнар ризык:

- 1-4 сыйныф укучылары өчен – икенче тапкыр түләүсез кайнар ризык;
- 5-11 сыйныф укучылары өчен – ике тапкыр кайнар ризык.

4) махсус медицина күрсәткечләре буенча өйдә белем алучыларга азык-төлек продуктлары җыелмасы бирү.

2 бүлек. Муниципаль гомуми белем бирү оешмасында
туклануны оештыру

2. Муниципаль гомуми белем бирү оешмасында укучыларның туклануын оештыру өчен, составы белем бирү оешмасы директоры тарафыннан раслана торган туклandыруны оештыру буенча комиссия (алга таба – комиссия) төзелә. Комиссия составына укучыларны туклandыруны оештыру өчен җаваплы педагогны, ата-аналар комитеты вәкилләрен кертергә

тәкъдим ителә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны биш кешедән ким булмаска тиеш.

3. Комиссия ай саен хисап аеннан соң килүче айның 25 числосына кадәр укучылар исемлеген раслый.

4. Гомуми белем бирү оешмасы директоры түбәндәгеләрне тәэмин итә:

1) гамәлдәге законнар нигезендә укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру һәм бюджет акчаларыннан максатчан файдалану, түләүсез кайнар ризык алган укучыларның факттагы санын исәпкә алу;

2) махсус медицина күрсәткечләре буенча өйдә белем алучы инвалид балаларга азык-төлек продуктлары җыелмасын түләүсез бирүне оештыру:

- 1-4 сыйныф укучылары өчен – икенче тапкыр бушлай кайнар ризык өчен;

- 5-11 сыйныф укучылары өчен – ике тапкыр кайнар ризык өчен;

3) түбәндәге исемлек нигезендә ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) документлар кабул итү эшен оештыру:

- әлеге нигезләмәгә кушымтада каралган форма буенча түләүсез кайнар ризык бирү турында гариза;

- күп балалы гаилә турында таныклык күчермәсе;

- балигъ булган баланың көндезге формасы буенча уку урыныннан белешмә;

- инвалидлык турында белешмә күчермәсе.

4) укучы белем бирү оешмасына кабул ителгәннән соң 10 эш көне эчендә, укучының мәктәп картасын әзерләү өчен, укучыны реестрга кертү өчен кирәкле мәгълүматларны (фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, туу датасы, җенесе, туу турында таныклык мәгълүматлары (биргән ил, РФ субъекты, сериясе, номеры һәм бирү датасы), паспорт (булганда), «Карта өчен фото» билгеләнгән фрагменты яки фотографиядән баш тартканда контур) кертеп, «Татарстан Республикасында электрон мәгариф» дәүләт мәгълүмат системасында укучының шәхси делосын тутыру буенча эшне оештыру.

5. Балигъ булмаган затларның ата-аналары яки башка законлы вәкилләре:

1) түләүсез кайнар ризык бирү өчен кирәкле, әлеге нигезләмәнең 4 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән документларны тапшыралар;

2) туклану картасы югалган яки бозылган очракта, укучының картасын әзерләү чорында туклануны оештыру өчен, бу хакта сыйныф җитәкчесенә яки укучыларны туклandыруны оештыру өчен җаваплы педагогка хәбәр итәләр.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларны түләүсез тукландыру тәртибе турында нигезләмәгә кушымта

(Форма)

Яр Чаллы шәһәренең
________________________ нче мәктәбе
укучыларының туклануын оештыру
буенча комиссиягә
____________________________________,
гариза бирүченең Ф.И.А.и.)

түбәндәге адрес буенча яшәүче:
_____________________________________

гариза.

Минем ____ сыйныфта укучы улым/кызым/опекага алынган балам (кирәклесенең астына сызарга)
_________________________________________________________________________
(Ф.И.А.и.)
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
бушлай тукландыруны сорыйм.

______ (дата)

_____________ (имза)

Башкарма комитетның
2021 елның 27 августындагы
5720 номерлы карарына
2 нче кушымта

Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучы
һәм 3 һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләрдә тәрбияләнүче
балаларның туклануын оештыруга чыгымнар
сметасы

| Балаларның гомуми саны | Көнгә уртача туклану бәясе (сум) | Көннәрнең гомуми саны | Барлыгы (сум) | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Муниципаль бюджет (сум) | Субвенция (сум) |
| 5 481 | 63,44 | 92 | 31 989 747 | 27 955 731 | 4 034 016 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2021 елның 27 августындагы
5720 номерлы карарына
3 нче кушымта

Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында
белем алучы инвалид балаларны тукландыруны оештыруга чыгымнар
сметасы

| Сыйныф | Балаларның гомуми саны | Көнгә уртача туклану бәясе (сум) | Көннәрнең гомуми саны | Барлыгы (сум) | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Муниципаль бюджет (сум) | Субвенция (сум) |
| 1-4 | 207 | 40,19 | 92 | 765 378 | 765 378 | 0 |
| 5-11 | 283 | 93,60 | 92 | 2 436 970 | 2 228 682 | 208 288 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева